УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ**

29.05.2023

Казан ш.

**БОЕРЫК**

№ 01-05/113 - пр

«Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау турында» 2021 елның 27 гыйнварындагы 01-05/40-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

1. 2021 елның 27 гыйнварындагы 01-05/40-пр номерлы боерык (2021 елның 4 мартындагы 01-05/68-пр номерлы, 2023 елның 1 мартындагы 01-05/63-пр номерлы боерыклар нигезендә кертелгән үзгәреше белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфасын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән башка квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүдән һәм шундый бәяләү һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп кую өчен дәгъва итүчеләр арасыннан гражданинны яки граждан хезмәткәрен билгеләүдән гыйбарәт.»;

1.9 пунктта:

өченче абзацта «кече вазыйфалар төркеменә» сүзләрен сүзләрне «кече вазыйфалар төркеменә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«федераль законнарда каралган башка очракларда.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Гражданин (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми:

а) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата, граждан хезмәте стажына яки белгечлек буенча эш, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле;

б) белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлек һәм әзерлек юнәлешләренең зурайтылган төркемнәренә), һөнәри яңадан әзерлекнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата квалификация таләпләренә (граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрендә шундый таләпләр каралган очракта) туры килмәве сәбәпле;

в) граждан хезмәтенә керү һәм аны узуга бәйле чикләүләргә һәм Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турында законнарына бәйле рәвештә.»;

3.4 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белем һәм (яки) квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданинның теләге буенча хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турындагы документлар күчермәләре;»;

4.1 пунктта «кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары» сүзләрен «кандидатларның һөнәри дәрәҗәсе, һөнәри һәм шәхси сыйфатлары» сүзләре белән алмаштырырга;

4.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитәкче карары буенча граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына карата граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларында конкрет белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләренең зур төркемнәренә), һөнәри яңадан әзерлекнең өстәмә һөнәри программасын үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә карата квалификация таләпләре билгеләнергә мөмкин.»;

4.5 пунктта:

беренче абзацта «оештыру-хокукый эш бүлеге» сүзләрен «оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданинның (граждан хезмәткәренең) һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше, һөнәри дәрәҗәгә квалификация таләпләренә, шулай ук, җитәкченең тиешле карары булганда – өстәмә яңадан һөнәри әзерлек үзләштерү нәтиҗәләре буенча белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (эреләндерелгән белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре төркемнәренә карата), квалификациягә карата таләпләргә туры килүен тикшерү.»;

4.11 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү;»;

4.12 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны белеме һәм (яки) квалификация турында, граждан яки башка дәүләт граждан хезмәтен үтү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында алар тарафыннан тапшырылган документларга нигезләнеп, шулай ук конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән кандидатлар биләү өчен дәгъва белдерә торган граждан хезмәте вакант

вазыйфасы буенча вазыйфа бурычларын үтәүгә бәйле мәсьәләләрдә, шәхси әңгәмә коруны, анкета сорауларына җавап алуны, төркемле дискуссияләр уздыруны, реферат яздыруны яисә тест уздыруны да кертеп, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын һөнәри дәрәҗәдәге бәяләү методларын кулланып бәяли. Конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә карап, төрле методлар кулланылырга мөмкин. Бу вакытта кандидат белән тест һәм индивидуаль әңгәмә уздыру барлык кандидатлар өчен дә мәҗбүри методлар булып тора.»;

4.16 пунктның беренче абзацында «һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган» сүзләрен «профессиональ дәрәҗәсе, һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2023 елның 29 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Җитәкче А.Ш.Борһанов